**Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы «Шланга авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Шланга авылында гражданнар җыены**
**КАРАРЫ**

**01 нче декабрь 2021 ел** **Шланга авылы** **№1**

**Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы “Шланга авыл җирлеге " муниципаль берәмлегендә Шланга авылы гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Шланга авыл җирлеге Уставының 12.1 статьясы, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Шланга авыл җирлеге Советы 10.10.2019 ел, № 44/1 карары белән расланган, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Шланга авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда, гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы Нигезләмә, 2021 елның 1 декабрендә төзелгән Хисап комиссиясенең, 2021 елның 1 декабрендә узган халык җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Гражданнар җыенында катнашучылар исемлегенә, тавыш бирү тәмамланган вакытта, җыенда катнашучы 487 кеше кертелгән, гражданнар җыенында катнашучыларның тавыш бирүдә катнашкан саны-**275**, бу исемлеккә кертелгән гражданнарның **56,47 %** тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

халык җыенында катнашкан **272** кеше «Әйе» позициясе өчен тавыш бирде, бу гражданнар җыенында тавыш бирүдә катнашучыларның **98,91%** ын тәшкил итә; «Каршы» позициясе өчен, җыенда катнашучы **3** кеше тавыш бирде, бу **1.09%** тәшкил итә.

Бәян ителгәннәр нигезендә карар иттеләр:

1. 2021 елның 1 декабрендә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының «Шланга авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Шланга авылында 2021 елның 1 декабрендә уздырылган гражданнар җыены нәтиҗәләрен-дөрес дип танырга.

2."Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының Шланга авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2022 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерергә:

- Шланга авылының Совет, Фрунзе һәм Киров урамнарының гамәлдәге юлларына вак таш салу;

- Шланга авылының К.Маркс урамы юл челтәрен ремонтлау;

- Ленин урамында 22а йорт адресы буенча, Шланга авылы мәдәният йорты янында урнашкан коены ремонтлау" дигән мәсьәлә буенча карар кабул ителгән дип танырга.

3. 2022 елда Чүпрәле муниципаль районының Шланга авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, балигъ булган һәр кешедән 500 сум күләмендә үзара салым акчасын кертергә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерергә:

- Шланга авылының Совет, Фрунзе һәм Киров урамнарының гамәлдәге юлларына вак таш салу;

- Шланга авылының К.Маркс урамы юл челтәрен ремонтлау;

- Ленин урамында 22а йорт адресы буенча, Шланга авылы мәдәният йорты янында урнашкан коены ремонтлау.

4. Әлеге карарны, Ленин урамы 22 а йортында, Шланга авыл җирлегенең Ленин урамы 32 нче йорт адресы буенча урнашкан Шланга авыл җирлегенең административ бинасында махсус мәгълүмат стендларында игълан итәргә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының рәсми сайтында Интернет-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль

Шланга авыл җирлеге башлыгы,

халык җыенында рәислек итүче: И.И.Якупов